**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«19» 09 2022 ел Яр Чаллы № 2615

Хисап чорына «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәген булдыру һәм эшләтү буенча эшче төркем киңәшмәсенең 2022 елның 1 июнендәге РН-12-135 номерлы беркетмәсенең 5 пунктын үтәү йөзеннән, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Хисап чорына «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының2022 елның «19» 09 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Хисап чорына «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорына «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 920 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм хисап чорына «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән күрсәткечләрне (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткечләр) җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели.

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирлар даими йөртүне гамәлгә ашыручы, акчасыз түләү системалары белән җиһазландырылган автобуслар өлеше,%;

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, алар өчен маршрут буенча реаль хәрәкәте турында ачык мәгълүмат тәэмин ителгән автобуслар өлеше, %;

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, шәхси мәгълүматларны яклау турында таләпләргә туры килә торган салоннарны видеокүзәтү системалары (язу функциясе белән) белән җиһазландырылган автобуслар өлеше, %.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек чикләрендә пассажирлар йөртүне оештыру җирле үзидарә органнары компетенциясенә керә.

Даими йөртү маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирла йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен, муниципаль район территориясендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан автобус пассажир транспорты хәрәкәтенең даими йөртү муниципаль маршрутлары исемлеген үз эченә алган шәһәр яны маршрут челтәре төзелә һәм раслана.

Татарстан Республикасы чикләрендә даими йөртү муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба - министрлык) тора.

Тукай муниципаль районында күрсәткеч зурлыгын җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге тора.

Күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль районында эшчәнлек алып баручы пассажир йөртүчеләр һәм йөк ташучылар бирә.

Күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүмат бирү формасы регламент кушымтасына туры килергә тиеш. Муниципаль район буенча берләштерелгән мәгълүмат аңа кергән җирлекләр мәгълүматларына нигезләнеп формалаша һәм регламент режимында Министрлыкка электрон документ әйләнеше ярдәмендә тапшырыла. Бер үк вакытта алынган һәм тапшырылган мәгълүмат Башкарма комитет җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән мәгълүмат җыю, мониторинглау һәм министрлыкка тапшыруны тәэмин итүче җаваплылык үзәге тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында архивлана.

## II. Төшенчәләр аппараты

Әлеге Регламентта кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә

пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 220-ФЗ номерлы федераль закон),«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә кулланыла.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Декомпозицияләнгән күрсәткечләрне исәпләү өчен түбәндәге ярдәмче күрсәткечләр кулланыла:

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) чикләрендә шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, акчасыз түләү системалары белән җиһазландырылган автобуслар өлеше;

муниципальара маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, акчасыз түләү системалары белән җиһазландырылган автобуслар өлеше;

муниципаль берәмлек (шәһәр округы) чикләрендә шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, алар өчен маршрут буенча реаль хәрәкәте турында ачык мәгълүмат тәэмин ителгән автобуслар өлеше;

муниципальара маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы, алар өчен маршрут буенча реаль хәрәкәте турында ачык мәгълүмат тәэмин ителгән автобуслар өлеше.

муниципаль берәмлек (шәһәр округы) чикләрендә шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, шәхси мәгълүматларны яклау турында таләпләргә туры килә торган салоннарны видеокүзәтү системалары (язу функциясе белән) белән җиһазландырылган автобуслар өлеше;

муниципальара маршрутлар буенча пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, шәхси мәгълүматларны яклау турында таләпләргә туры килә торган салоннарны видеокүзәтү системалары (язу функциясе белән) белән җиһазландырылган автобуслар өлеше;

Декомпозицияләнгән күрсәткечләрне исәпләү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы автобусларның гомуми саны;

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, акчасыз түләү системалары белән җиһазландырылган автобуслар саны;

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, алар өчен маршрут буенча реаль хәрәкәте турында ачык мәгълүмат тәэмин ителгән автобуслар саны;

шәһәр, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәдә (Татарстан Республикасы чикләрендә) пассажирларны даими йөртүне гамәлгә ашыручы, шәхси мәгълүматларны яклау турында таләпләргә туры килә торган салоннарны видеокүзәтү системалары (язу функциясе белән) белән җиһазландырылган автобуслар саны.

220-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә даими йөртүләр муниципаль маршруты, даими йөртүләр муниципальара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары даими йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс нәтиҗәләре буенча министрлык яки Башкарма комитет тарафыннан бирелә.

Җайга салынулы тарифлар буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыру, 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә контрактлар төзү юлы белән тәэмин ителә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр, муниципаль контракт төзелгән яисә даими йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән шартнамәдә вәкаләтле катнашучыдаими йөртүләрне гамәлгә ашыру турында кушымта нигезендә кварталлык хисаплар җибәрергә тиеш.

Мәгълүмат Башкарма комитетның җаваплылык үзәгенә – төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегенә электрон рәвештә электрон документ әйләнешендә яки җитәкче имзасы һәм мөһере белән электрон почта адресына тапшырыла. Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты электрон формада кергән мәгълүматны кушымта нигезендә исәпкә ала һәм хисап аеннан соң килүче айның 3 числосыннан да соңга калмыйча, аны электрон документ әйләнеше системасын кулланып министрлыкка тапшыра.

Мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү нәтиҗәләре буенча хисап аеннан соң килгән айның 8 числосына кадәр Министрлык тарафыннан Федераль дәүләт мәгълүматны контрольдә тоту мәгълүмат системасында (ФГИС КИ) күрсәтелгән күрсәткечләрне үтәү буенча мәгълүмат тутырыла.

1. Автобусларны акчасыз түләү системалары, салоннарны техник күзәтү чаралары (язу функциясе белән) һәм GPS/ГЛОНАСС аппаратурасы белән җиһазлау буенча «Җәмәгать транспорты» тармагының «Цифрлы өлгереш» күрсәткече буенча мәгълүматларны мониторинглау формасы

| № | Район исеме | Пассажир йөртүче исеме | Пассажирларны даими йөртүче автобусларның гомуми саны, берәмлек | шәһәр эчендәге һәм муниципалитет эчендәге элемтә | | | | шәһәр яны элемтәсе | | | | муниципальара элемтә | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлык т.ч. | шулардан җиһазландырылган: | | | Барлык т.ч. | шулардан җиһазландырылган: | | | Барлык т.ч. | шулардан җиһазландырылган: | | |
| | | | | | йөрү өчен акчасыз түләү системасы, берәмлек | салоннарны видеокүзәтү системасы, берәмлек | GPS/ГЛОНАСС спутник навигация аппаратурасы (маршрут буенча аларның реаль хәрәкәте турында мәгълүматны онлайн карау мөмкинлеге белән), берәмлек | | йөрү өчен акчасыз түләү системасы, берәмлек | салоннарны видеокүзәтү системасы, берәмлек | GPS/ГЛОНАСС спутник навигация аппаратурасы (маршрут буенча аларның реаль хәрәкәте турында мәгълүматны онлайн карау мөмкинлеге белән), берәмлек | | йөрү өчен акчасыз түләү системасы, берәмлек | салоннарны видеокүзәтү системасы, берәмлек | GPS/ГЛОНАСС спутник навигация аппаратурасы (маршрут буенча аларның реаль хәрәкәте турында мәгълүматны онлайн карау мөмкинлеге белән), берәмлек |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | |